**10 нчы сыйныф**
**1 нче вариант**

**А1.** *Бизнес* **сүзенең кайсы телдән кергәнлеген күрсәтегез (2 балл).**

1) рус теленнән
2) гарәп теленнән
3) **инглиз теленнән**
4) испан теленнән

**А2. Күп нокталар урынына *х* хәрефе язылырга тиешле очракны күрсәтегез (2 балл).**

1) ка...арман, ...ава
2) бини...ая, ни...аять
3) ...әр, Ил...ам
4) **бә...әс, а...ыр**

**А3. Антонимнарны табыгыз (2 балл).**

1) зур – олы
2) **нечкә – юан**
3) куллану - файдалану
4) мул – бай

**А4. Тамыр сүзне күрсәтегез (2 балл).**

1) мәктәптә
2) кулъяулык
3) **апа**
4) егетлек

**А5. Морфологик принципка буйсынып язылган очракны күрсәтегез (2 балл).**

1) өстәлдә
2) телевизорның
3) китапларда
4) **томанлы**

**А6. Сөйләм төгәллеге бозылган җөмләне күрсәтегез (3 балл).**

1) Әнием Сара апаның бер алдына, биш артына төште.
2) **Менә ничек сайрый башлады безнең сандугачыбыз!**
3) Юл буе безне тургайлар сайравы озата барды.

4) Мәктәпкә кергәч, Гәүһәрнең бөтен уйларын балалар биләп алды.

**А7. Әдәби тел нормаларын бозып әйтү бирелгән рәтне күрсәтегез (3 балл).**

1) [а$^{о}$ңкау] [күтәреңке]
2) **[сәлгә], [былыт]**
3) [сөт], [тирәк]
4) [әңгәмә], [сыңған]

**А8. Кайсы җөмләдә *борын* сүзе туры мәгънәдә кулланылган? (3 балл).**

**1) Эт, борынын сузып, һаваны иснәде.**
2) Күтәрмә борыныңны, өзәрләр муеныңны!
3) Самавыр борыныннан су тамып тора.
4) Көймә борыны белән ярга төртелде.

**А9. Сүзтезмәнең төрен билгеләгез (3 балл)**

*егерме алма*

1) рәвешле сан сүзтезмә
2) санлы рәвеш сүзтезмә
3) алмашлыклы сан сүзтезмә
**4) санлы исем сүзтезмә**

**А10. Җөмләдә аерымланган хәлнең төрен күрсәтегез (3 балл).**

*Өйләренә кайтып җитсә, Айдар бөтен җыйганын әнисенә бирер иде.*

1) вакыт хәле
**2) шарт хәле**
3) сәбәп хәле
4) урын хәле

**А11. Сингармонизм законының рәт гармониясенә буйсынмаган сүз кулланылган җөмләне күрсәтегез. (3 балл)**

1) **Абыем, әйт, зинһар, ашыгып, кая, нигә очабыз без?**
2) Урманнарны, тауларны агартырга, басуларны җылытырга.
3) Оча-оча авыл урамына килеп керде Фирүзә.
4) Фирүзә кызчыкның алсу учына очып төште.

**А12. Тартык авазларның әйтелеш һәм язылышлары туры килмәгән төркемне күрсәтегез. (3 балл)**

**1) тавык, карга, әнкәй**
2) кино, вагон, сан
3) кинәт, зәңгәр, шат

4) бара, мөмкин, театр

**А13. Кайсы сүз башкаларыннан аерылып тора? (3 балл)**

1) утау
2) утлау
3) утлык
**4) утын**

**А14. Кайсы вариантта киләчәк заман хикәя фигыль кушымчасы дөрес күрсәтелгән? (3 балл)**

**1) гөрелдә - р**
2) йөре - р
3) чүп -ләр
4) кит-ерер

**А15. Кайсы вариантта асыл сыйфатлардан гына торган төркем бирелгән? (3 балл)**

1) язгы, зур, матур
2) яшел, кисек, кояшлы
**3) караңгы, кызыл, аксыл**
4) саргылт, өстәмә, алынма

**В1.** ***Аның янында кемнәрдер бар < ... > ә эти арттан атлый. (К. Тимбикова) җ*өмләсендә <...> тамгасы урынына нинди тыныш билгесе куелырга тиешлеген языгыз. (4 балл).**

**Җавап (Ответ): ӨТЕР**
Инструкция: Сүзне БАШ хәрефләр белән баш килештә, берлек санда языгыз.

**В2.** ***Әни җыры < ... > дөньядагы иң бөек җыр җ*өмләсендә <...> тамгасы урынына нинди тыныш билгесе куелырга тиешлеген языгыз. (4 балл).**

**Җавап (Ответ): СЫЗЫК**
Инструкция: Сүзне БАШ хәрефләр белән баш килештә, берлек санда языгыз.

**В3.** *Язык* **искергән сүзенең хәзерге телдә кулланыла торган вариантын языгыз (4 балл).**

**Җавап (Ответ): ГӨНАҺ**

Инструкция: Сүзне БАШ хәрефләр белән баш килештә, берлек санда языгыз.

**B4.** *Баргалый, көлемсери, караштыра* **сүзләре кайсы сүз төркеменә керә? (4 балл).**

**Җавап (Ответ): ФИГЫЛЬ/ ФИГЫЛЬЛӘР**
Инструкция: Сүзне БАШ хәрефләр белән баш килештә, берлек санда языгыз.

**B5.** ***Әйтче, чишмәм, ничек кенә итеп сиңа җан кертим соң? җөмләсеннән* эндәш сүзне күчереп алыгыз. (4 балл).**

**Җавап (Ответ): ЧИШМӘМ**
Инструкция: Сүзне БАШ хәрефләр белән җөмләдәге формада күчереп языгыз.

**B6.** *Кешеләр җирдә яңа матурлык тудыру өчен эзләнәләр, максатларына ирешү өчен күпме көч куялар.* **җөмләсеннән ясалма исемне күчереп алыгыз. (4 балл).**

**Җавап (Ответ): МАТУРЛЫК**
Инструкция: Сүзне БАШ хәрефләр белән җөмләдәге формада күчереп языгыз.

**B7. Җөмләдән ирен гармониясенә буйсынган сүзне күчереп алыгыз:** *Без әни җырын дистә еллар үткәч тә, тормышыбызның иң авыр һәм иң бәхетле сәгатьләрендә искә төшерәбез. (Р. Гамзатов)* **(4 балл).**

**Җавап (Ответ): ТОРМЫШЫБЫЗНЫҢ**
Инструкция: Сүзне БАШ хәрефләр белән җөмләдәге формада күчереп языгыз.

**B8. Җөмләдәге аерып бирелгән сүз нинди җөмлә кисәге булып килә?** *Алар* ***кузгаткан*** *дулкыннарда шәфәкъ яктысы ялкын телләредәй уйный.* **(4 балл).**

**Җавап (Ответ): АЕРГЫЧ**
Инструкция: Сүзне БАШ хәрефләр белән баш килештә, берлек санда языгыз.

**B9.** ***Дөнья... матур җирләре күп, ләкин туган яктан да кадерлерәк җир юктыр* җөмләсендә нокталар урынына кайсы килеш кушымчасын куярга кирәк?**

**Җавап (Ответ): ИЯЛЕК /ИЯЛЕК КИЛЕШЕ**
Инструкция: Сүзне БАШ хәрефләр белән баш килештә, берлек санда языгыз.

**B10. Тәңгәллек урнаштырыгыз (4 балл).**

| | |
|---|---|
| А) каен җиләге | 1) тамыр сүз |
| Б) болын | 2) ясалма сүз |
| В) аксакал | 3) саф кушма сүз |
| Г) кыргыч | 4) тезмә сүз |

**Җавап (Ответ): 4132**
ИНСТРУКЦИЯ:

Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

**B11. Бирелгән сүзләрнең тәрҗемәсе дөрес күрсәтелгән очракларны тәңгәллек белән күрсәтегез (4 балл).**

| СҮЗ | ТӘРҖЕМӘСЕ |
|---|---|
| А) кылыч | 1) подогнуть |
| В) бөкләү | 2) будущее |
| В) туңдырма | 3) сабля |
| Г) киләчәк | 4) мороженое |

**Җавап (Ответ): 3142**

ИНСТРУКЦИЯ:
Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

**B12. Ике өлешне туры китереп, дөрес тотрыклы әйтелмәләр барлыкка китерегез (4 балл).**

| | |
|---|---|
| А) киләп | 1) сөте генә юк |
| Б) күгәрчен | 2) сарып йөрү |
| В) ат ачуын | 3) заманыннан бирле |
| Г) нух | 4) тәртәдән алу |

**Җавап (Ответ): 2143**

ИНСТРУКЦИЯ:

Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

**В13. Сүзләрнең мәгънәләре арасында тәңгәллек урнаштырыгыз. (4 балл)**

| СҮЗ | МӘГЪНӘСЕ |
|---|---|
| А) кырку | 1) янып сүнгән агач кисәге |
| В) кисәү | 2) артык әче |
| В) иңелү | 3) чокырланып керү |
| Г) имәнү | 4) куркып китү |

**Җавап (Ответ): 2134**

ИНСТРУКЦИЯ:

Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

**В14. Тәңгәллекләр урнаштырыгыз (4 балл)**

| | |
|---|---|
| А) якыннарыгызга игътибарлы булыгыз | 1) хикәя фигыль |
| Б) тормышка дәртен сиздергән булган | 2) инфинитив |
| В) ат сакларга кирәк | 3) боерык фигыль |
| Г) аларны үстергән кара тавыкка рәхмәт | 4) сыйфат фигыль |

**Җавап (Ответ): 3124**

ИНСТРУКЦИЯ:

Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

**В15. Тәңгәллек урнаштырыгыз (4 балл).**

| | |
|---|---|
| А) тамыр исем | 1) рәхмәт уку |
| Б) ясалма рәвеш | 2) миләш |
| В) саф кушма сыйфат | 3) каракучкыл |
| Г) тезмә фигыль | 4) күбесенчә |

**Җавап (Ответ): 2431**

ИНСТРУКЦИЯ:

Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

**10 нчы сыйныф**
**2 нче вариант**

**А1.** *Кыйммәт* **сүзенең кайсы телдән кергәнлеген күрсәтегез (2 балл).**

5) рус теленнән
**6) гарәп теленнән**
7) инглиз теленнән
8) испан теленнән

**А2. Күп нокталар урынына *һ* хәрефе язылырга тиешле очракны күрсәтегез (2 балл).**

**1) ка...арман, ...ава**
2) ...әлсез, и...тыяр
3) ...аят, и...тирам
4) бә...әс, а...ыр

**А3. Антонимнарны табыгыз (2 балл).**

1) иске– сәләмә
**2) биек – тәбәнәк**
3) җан - кот
4) сандугач – былбыл

**А4. Тамыр сүзне күрсәтегез (2 балл).**

1) сабакташ
2) аксакал
**3) исем**
4) иркәләнү

**А5. Морфологик принципка буйсынып язылган очракны күрсәтегез (2 балл).**

1) ташбаш
2) машинадан
3) тәрәзәләр
**4) салынкы**

**А6. Сөйләм төгәллеге бозылган җөмләне күрсәтегез (3 балл).**

**1) Йөри торгач, өченче чыршыны очратты ул урманда.**
2) Тиз арада чәй кайнап чыккан.
3) Моны күрүгә, егетләр, бер-берсен бүлдереп, бүләкне мактарга тотындылар.
4) Ул халык авыз иҗатын җыюга зур көч куя.

**А7. Әдәби тел нормаларын бозып әйтү бирелгән рәтне күрсәтегез (3 балл).**
1) [а°лма] [иртәңгә]
2) **[тэлкэ], [бырын]**
3) [сөт], [тирәк]
4) [әңгәмә], [сәләмәт]

**А8. Кайсы җөмләдә *авыз* сүзе туры мәгънәдә кулланылган? (3 балл).**
**1) Малай, авызын зур ачып, бу тамашага карап торды.**
2) Аны мич авызы каршында керләр уып торган хатыны каршылады.
3) Бер кулы белән баз авызының бурасына ябышты.
4) Кайдадыр җир тетри, кайдадыр янартаулар авызыннан ут чәчелә.

**А9. Сүзтезмәнең төрен билгеләгез (3 балл)**
*Җиденче сыйныф*
1) рәвешле сан сүзтезмә
2) санлы рәвеш сүзтезмә
3) алмашлыклы сан сүзтезмә
**4) санлы исем сүзтезмә**

**А10. Җөмләдә аерымланган хәлнең төрен күрсәтегез (3 балл).**
*Ярсып китүенә карамастан, мин аны аңларга тырышам.*
1) вакыт хәле
**2) кире хәл**
3) сәбәп хәле
4) урын хәле

**А11. Сингармонизм законынының рәт гармониясенә буйсынмаган сүз кулланылган җөмләне күрсәтегез. (3 балл)**
1) **Ул бер минутка гына тынып калды, тирән уйга батты.**
2) Хәмит мәктәпкә йөри башлады.
3) Очраклы бер хәл аңа бу авыр мәсьәләне чишәргә ярдәм итте.
4) Шундый икеләнүләр торган саен тирәнәя барды.

**А12. Тартык авазларның әйтелеш һәм язылышлары туры килмәгән төркемне күрсәтегез. (3 балл)**

**1) савыт, газиз, төнбоек**

2) телевизор, матур, тизрәк
3) аксыл, тирән, барачак
4) укытучы, өстәл, йөгерде

**А13. Кайсы сүз башкаларыннан аерылып тора? (3 балл)**

1) утау
2) утлау
3) утлык
**4) утын**

**А14. Кайсы вариантта киләчәк заман хикәя фигыль кушымчасы дөрес күрсәтелгән? (3 балл)**

**1) дөбердә - р**
2) бары - р
3) аш -ар
4) җит-керер

**А15. Кайсы вариантта асыл сыйфатлардан гына торган төркем бирелгән? (3 балл)**

5) кышкы, зур, матур
6) ак, кисек, яңгырлы
**7) сары, кызгылт, зәңгәрсу**
8) саргылт, ямьле, җәйге

**В1.** ***Әллә тавышларыбызга игътибар итеп < ... > бөркетләрнең икенчесе дә аваз салды. (Ф. Яхин)*** **җөмләсендә <...> тамгасы урынына нинди тыныш билгесе куелырга тиешлеген языгыз. (4 балл).**

**Җавап (Ответ): ӨТЕР**
Инструкция: Сүзне БАШ хәрефләр белән баш килештә, берлек санда языгыз.

**В2.** ***Исәбе < ... > кеше күзенә эләкмәү*** **җөмләсендә <...> тамгасы урынына нинди тыныш билгесе куелырга тиешлеген языгыз. (4 балл).**

**Җавап (Ответ): СЫЗЫК**
Инструкция: Сүзне БАШ хәрефләр белән баш килештә, берлек санда языгыз.

**В3.** *Кот* **искергән сүзенең хәзерге телдә кулланыла торган вариантын языгыз (4 балл).**

**Җавап (Ответ): ҖАН**

Инструкция: Сүзне БАШ хәрефләр белән баш килештә, берлек санда языгыз.

**B4.** *Карана, уйлата, сөйләндерә* **сүзләре кайсы сүз төркеменә керә? (4 балл).**

**Җавап (Ответ): ФИГЫЛЬ/ ФИГЫЛЬЛӘР**
Инструкция: Сүзне БАШ хәрефләр белән баш килештә, берлек санда языгыз.

**B5.** ***Әй, авылым, син минем бишегем. җөмләсеннән* эндәш сүзне күчереп алыгыз. (4 балл).**

**Җавап (Ответ): АВЫЛЫМ**
Инструкция: Сүзне БАШ хәрефләр белән җөмләдәге формада күчереп языгыз.

**B6.** *Кечкенә шәһәрнең авыл урамы шикелле ямь-яшел чирәмендә яланаяк йөгерә кыз бала.* **җөмләсеннән саф кушма исемне күчереп алыгыз. (4 балл).**

**Җавап (Ответ): ЯЛАНАЯК**
Инструкция: Сүзне БАШ хәрефләр белән җөмләдәге формада күчереп языгыз.

**B7. Җөмләдән ирен гармониясенә буйсынган сүзне күчереп алыгыз:** *Һавада кыр казларының моңсу гына тонык тавышлары ишетелде. (Д. Гайнетдинова)* **(4 балл).**

**Җавап (Ответ): ТОНЫК**
Инструкция: Сүзне БАШ хәрефләр белән җөмләдәге формада күчереп языгыз.

**B8. Җөмләдәге аерып бирелгән сүз нинди җөмлә кисәге булып килә?** ***Өрфия*** *болытлар җил уңаена агыла да агыла.* **(4 балл).**

**Җавап (Ответ): АЕРГЫЧ**
Инструкция: Сүзне БАШ хәрефләр белән баш килештә, берлек санда языгыз.

**B9.** ***Чишмә… берни белән дә чагыштырып булмый торган моңлы агышына сандугачлар тавышы кушыла җөмләсендә* нокталар урынына кайсы килеш кушымчасын куярга кирәк? (4 балл).**

**Җавап (Ответ): ИЯЛЕК /ИЯЛЕК КИЛЕШЕ**
Инструкция: Сүзне БАШ хәрефләр белән баш килештә, берлек санда языгыз.

**B10. Тәңгәллек урнаштырыгыз (4 балл).**

| | |
|---|---|
| А) кура җиләге | 1) тамыр сүз |
| Б) урман | 2) ясалма сүз |
| В) өчпочмак | 3) саф кушма сүз |
| Г) бүлмә | 4) тезмә сүз |

**Җавап (Ответ): 4132**
ИНСТРУКЦИЯ:

Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

**B11. Бирелгән сүзләрнең тәрҗемәсе дөрес күрсәтелгән очракларны тәңгәллек белән күрсәтегез (4 балл).**

| СҮЗ | ТӘРҖЕМӘСЕ |
|---|---|
| А) клевать | 1) үрнәк |
| Б) обижаться | 2) чүпләү |
| В) образец | 3) кайнатма |
| Г) варенье | 4) үпкәләү |

**Җавап (Ответ): 2413**

ИНСТРУКЦИЯ:
Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

**B12. Ике өлешне туры китереп, дөрес тотрыклы әйтелмәләр барлыкка китерегез (4 балл).**

| | |
|---|---|
| А) алтын | 1) икенчесен эт ашый |
| Б) бер аягын атлаганчы, | 2) һәр ялтыраган ... түгел |
| В) бар чакта бүредәй, | 3) аннан эшлә |
| Г) алдан уйла, | 4) юк чакта шүредәй |

**Җавап (Ответ): 2143**

ИНСТРУКЦИЯ:

Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

**В13. Сүзләрнең мәгънәләре арасында тәңгәллек урнаштырыгыз. (4 балл)**

| СҮЗ | МӘГЪНӘСЕ |
|---|---|
| А) ачыныш | 1) җиңелчә ыңгырашу |
| Б) сыкрану | 2) авыр кайгы |
| В) иңкәю | 3) аву |
| Г) имрәтү | 4) куркыту |

**Җавап (Ответ): 2134**

ИНСТРУКЦИЯ:

Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

**В14. Тәңгәллекләр урнаштырыгыз (4 балл)**

| | |
|---|---|
| А) якыннарыгызга игътибарлы булыгыз | 1) хикәя фигыль |
| Б) тормышка дәртен сиздергән булган | 2) инфинитив |
| В) ат сакларга кирәк | 3) боерык фигыль |
| Г) аларны үстергән кара тавыкка рәхмәт | 4) сыйфат фигыль |

**Җавап (Ответ): 3124**

ИНСТРУКЦИЯ:

Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

**В15. Тәңгәллек урнаштырыгыз (4 балл).**

| | |
|---|---|
| А) тамыр сүз | 1) буар елан |
| Б) ясалма сүз | 2) дәфтәр |
| В) саф кушма сүз | 3) чәчүргеч |
| Г) тезмә сүз | 4) дәгъвалау |

**Җавап (Ответ): 2431**

ИНСТРУКЦИЯ:

Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.